# Мастер-класс

## Ата-аналар җыелышы



# Тема: Кече яшьтәге мәктәп балаларының уку эшчәнлеген оештыруда гаиләнең роле

**Бурычлар:** 1.Балаларның өйдә дәрес әзерләвен оештырырга өйрәтү.
2.Өйгә бирелгән эшне мөстәкыйль үтәүләренә ирешү.
3.Балага уку күнекмәсен биргәндә ата-аналарның тәрбиялек культурасын формалаштыру.
4.Балаларга укуда ярдәм күрсәтү төрләре белән таныштыру
5.Әти - әниләр һәм балалар арасын якынайту.

**Үткәрү формасы :** түгәрәк өстәл.

**Җиһазлау :** анкеталар,педагогик ситуацияләр,ата-аналарга киңәшләр, укучыга истәлек,практик тәкъдимнәр белән ата-аналарга буклет.

" Бала яхшы укуының 80 % аның гаиләсенә бәйле "

**Антуан де ла Гарандери**

# Дәрес әзерләүне дәрес оештыру өчен кирәкле шартлар :

- уку почмагы булдыру.
- көндәлек режимны үтәү.
- өй эшен системалы эшләргә өйрәтү.
- дәрес әзерләгәндә балага комаучаламау.
- мөстәкыйль шөгыльләнергә мөмкинлек бирү.



# Укучы өчен истәлек



Дәрес әзерләргә утырабыз.


- Дәрес әзерләргә һәрвакыт бер үк вакытта утыр.
- Эшкә тотынганчы бүлмәне җиллләт.
- Радио һәм телевизорны сүндер.Бүлмәдә тавыш булмаска тиеш.
- Өстәлеңне тәртипкә китер .
- Алдагы көн расписаниесен барла.Көндәлеккә барлык өй эшләре дә язылганмы.
- Уку кирәк-яракларын әзерлә.
- Эшләргә вакыт җитте.

Дәреслегеңне ач.

**Башлангыч сыйныфларда өй эшләрен әзерләү өчен**

- *2 сыйныф* – 1,5 сәгать
- *3 сыйныф* – 2 сәгать
- *4 сыйныф* – 2,5 сәгать

**вакыт сарыф ителә.**



# Педагогик ситуация

- Бер гаиләдә баладан көн саен :" Бүген мәктәптән нинди билге алып кайттың?"- дип сорыйлар. Бала : "3" ле яки "4" ле алдым дип җавап бирә .Ата-ана шуның белән тынычлана.Сорау: балаларның укулары белән даими кызыксынып торган гаилә әлеге сорауны ничегрәк бирер иде икән?
- Кайбер гаиләләрдә шундый фикер яши :"Мин дә ,әтисе дә көчкә-көчкә "3" кә укыдык, балабыз да шуннан арттырмас инде".Сез нинди фикердә?



Анкета

# Анкета

## (Ата-аналар өчен)



1.Баланың укуы белән даими кызыксынасызмы ?

2.Дәрес әзерләргә кем булыша?

3.Көннең ничә сәгатен балагызга багышлыйсыз?

4.Балагыз ничә сәгать дәрес әзерли?

5.Кайсы фәннәр вакытны күбрәк таләп итә?

6.Буш вакытларны балагыз белән үткәрәсезме ?Кайда һәм ничек?

# Нәтиҗә

1.Әйе

2.Әти һәм әни

3.1,5сәг.-2 сәг.

4. 2 сәгать

5.Математика

6.Әйе.     Әңгәмә үткәрү ,уеннар  уйнау, телевидение тапшырулары карау һәм фикер алышу.

# Анкета

## (Укучылар өчен)

1.Дәрес әзерләргә сиңа кем булыша?

2.Сиңа ничек ярдәм итәләр?

3.Өй эшен әзерләүгә күпме вакыт сарыф итәсең?

4.Синең укуың ,тәртибең белән ничек кызыксыналар?

5.Нәрсә өчен мактыйлар , ни өчен ачуланалар ?

6.”2” ле алып кайтсаң , нинди чара күрәләр?

7.Буш вакытыңда нәрсәләр эшлисең?






# Ата-анага киңәшләр

- Баланы йокыдан тыныч кына уятыгыз,ул сезнең елмаюыгызны күрсен һәм йомшак тавышыгызны ишетсен , иртәдән үк баланы юк-бар өчен шелтәләмәгез.
- Баланы мәктәпкә озатканда аңа уңышлар теләгез , ягымлы сүзләр әйтегез.
- Баланы мәктәпкә иртәнге ашны ашатмыйча озатмагыз.Аны алда авыр хезмәт – уку хезмәте көне көткәнен онытмагыз.
- Баланы мәктәптән тыныч каршы алыгыз.Әгәр бала ни өчендер ярсыган, сезнең белән борчуларын бүлешергә тели икән , аны тыңлагыз.
- Баланың борчылганын күрсәгез , тик ул борчылуын сезнең белән уртаклышырга теләмәсә , сорашмавыгыз хәерлерәк.Бала тынычлансын, үзе үк барысын да сөйләр.
- Мәктәптән кайткач та баланы дәрес хәзерләргә утыртмагыз.Бала 2-3 сәгать ял итеп алсын (I сыйныфлар 1,5 сәгать йоклап алсалар , тагын да яхшырак).Дәрес әзерләү өчен иң яхшы вакыт-көндезге сәгать 3тән 5 кә кадәр , ә кич белән дәрес әзерләргә бөтенләй киңәш ителми.
- Барлык фәннәрдән дә дәрес әзерләүне бер утыруда башкарырга мәҗбүр итмәгез.20-25 минут шөгыльләнгәннән соң ,10-15 минутлык ял кирәк.
- Дәрес әзерләгәндә балага мөстәкыйль шөгыльләнергә мөмкинлек бирегез.Әгәр сезнең ярдәм кирәк булса , сабыр булыгыз.Аңа борчылмаска кушыгыз, уңышларын күрегез , мактап алыгыз.
- Баланың :”Баш авырта,ардым,үземне начар хис итәм”,-дип зарлануларына игътибарлы булыгыз.Болар-укудагы кыенлыклар нәтиҗәсе.
- Хәтта “зур” балалар да йокларга ятар алдыннан әкият,җыр тыңларга , баштан сыйпатырга ярата.Бу аларны тынычландыра ,киеренкелекне бетерергә ,тыныч йоклап китәргә мөмкинлек бирә.



# Педагогик өчпочмак



Хөрмәтле ата-аналар !

*Сезгә ныклы сәламәтлек ,гаилә бәхете,эшегездә уңышлар  телим!Балаларыбыз бары тик шатлык – сөенечләр генә китерсен!*

